КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 22 август г.Казань № 723

Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясе турында

Вокал сәнгате эшлеклеләренең иҗади потенциалын стимуллаштыру, милли вокал традицияләрне саклау, вокал сәнгатендә югары осталыкка ирешкән өчен дәүләт бүләкләре бирү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясе 2021 елдан башлап ике елга бер тапкыр бирелә.

2. Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясен бирү буенча комиссия төзергә.

3. Түбәндәгеләрне расларга:

Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясе турында нигезләмә;

Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясен бирү комиссиясе турында нигезләмә;

Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясен бирү комиссиясе составы.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына 2021 елдан башлап Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясен бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан 600,0 мең сум күләмендә акча бүлеп бирүне тәэмин итәргә.

5. Бк карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар
Кабинетының 2020 ел, 22
август, 723 нче карары
белән расланды

Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясе турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Илһам Шакиров исемендәге республика премиясе (алга таба – Премия) башкаручыларга милли вокал сәнгате өлкәсендә югары иҗтимагый танылу алган иң күренекле казанышлары, башкару осталыгы һәм татар җыр мәдәниятенең элеккеге традицияләрен саклап калу һәм популярлаштыру, профессиональ җыр һәм вокал иҗатны үстерү буенча нәтиҗәле эшчәнлеге өчен бирелә.

1.2. Премия Премия алуга кандидатны тәкъдим итү турындагы гаризаларны (алга таба – гариза) карау нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә форма буенча бирелә.

1.3. Премияне Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясен бирү комиссиясе (алга таба – Комиссия) оештыра.

1.4. Премия Комиссия тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән бирелә.

1.5. Премия шәхси характерда һәм түбәндәге номинацияләр буенча һәм түбәндәге күләмнәрдә бирелә:

«Вокал (хатын-кызлар)» – 2 00,0 мең сум күләмендә бер премия;

«Вокал (ир-атлар)»– 200,0 мең сум күләмендә бер премия;

«Халык җыры» – 200,0 мең сум күләмендә бер премия.

1.6. Премиягә лаек булган затларга «Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясе лауреаты» исеме бирелә, акчалата бүләк, диплом, Премия лауреатының мактау билгесе һәм аңа таныклык тапшырыла.

1.7. Премия Илһам Шакировның туган көненә багышланган тантаналы шартларда ике елга бер тапкыр тапшырыла.

1.8. Премия лауреатка кабат бирелә алмый.

1.9. Премияне бирүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

1.10. Премия бирү өчен каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүче – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы.

## II. Премиягә кандидатларны тәкъдим итү тәртибе

2.1. Премияне алу өчен башкаручы әлеге Нигезләмәнең 1.1 пункты нигезендә

(алга таба – Премиягә кандидат) тәкъдим ителергә мөмкин.

Премиягә коллективларны тәкъдим итү башкарылмый.

2.2. Премияне алу өчен үлгәннән соң тәкъдим ителми.

2.3. Мәдәният өлкәсендә дәүләт әһәмиятендәге башка премияләренә лаек булган яки тәкъдим ителгән башкаручы Премия бирелгән елда Премиягә тәкъдим ителә алмый.

2.4. Премиягә кандидатны тәкъдим итү Татарстан Республикасы территориясендә эш итүче иҗтимагый оешмалар, фәнни оешмалар, мәдәният оешмалары, белем бирү оешмалары (алга таба – Премиягә кандидатлар тәкъдим иткән оешмалар) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.5. »Халык җыры» номинациясендә премиягә үз-үзләрен тәкъдим итү рөхсәт ителә.

2.6. Премиягә кандидатлар оешмаларның коллегияләр, президиумнар, идарәләр, сәнгать һәм галимнәр советлары утырышларында, хезмәт коллективлары җыелышларында тәкъдим ителә.

2.7. Премиягә кандидатны тәкъдим иткәндә түбәндәге документлар тапшырыла:

гариза;

Премиягә кандидатны тәкъдим иткән оешманың Премиягә кандидатны тәкъдим итү турында карары (әлеге Нигезләмәнең 2.4 пункты нигезендә кандидатны тәкъдим иткән очракта);

Премиягә кандидатның иҗади эшчәнлеге турында белешмә;

Премиягә кандидатның иҗади портфолиосы (репертуар, концерт программасы, фоторәсемнәр, аудио-һәм видеоматериаллар, башка күрсәтмә материал);

Премиягә кандидатның иҗатын киң җәмәгатьчелек тарафыннан танылуын раслаучы документлар (публикацияләр, рецензияләр, массакүләм мәгълүмат чараларында фикерләр, белгечләр бәяләмәләре);

Премиягә кандидатның паспорты яки шәхесен таныклаучы башка документы күчермәсе;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча гражданның бурычы булмавы турында белешмә;

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

Документларга исемлек теркәлә.

2.8. Бер оешма тарафыннан Премиягә берничә кандидатны тәкъдим иткәндә аларның һәркайсына әлеге Нигезләмәнең 2.7 пунктында күрсәтелгән документларның аерым комплекты төзелә.

2.9. Документлар Премия бирү елында 1 августтан 15 ноябрьгә кадәр кәгазьдә рәвештә кулга йә почта элемтәсе (курьер хезмәте) аша Комиссиягә 420015, Казан ш., Пушкин ур., 66/33 йорт, 114 нче кабинет адресы буенча тапшырыла.

2.10. Әлеге Нигезләмәнең 2.7 пунктында күрсәтелгән Премиягә тапшырылган документлар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

2.11. Гаризалар кабул итү вакыты тәмамланганнан соң Комиссиягә кергән документлар (шул исәптән почта аша, курьер хезмәте аша) каралуга рөхсәт ителми.

### III. Премиягә кандидатларны сайлап алу критерийлары һәм аларга таләпләр

3.1. Премиягә кандидатларны сайлап алу белән бәйле оештыру-техник мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына (алга таба – вәкаләтле орган) йөкләнә.

3.2. Документлар тапшыру срогы тәмамланганнан соң, эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә вәкаләтле орган боерыгы белән эксперт советы раслана.

3.3. Эксперт советының максаты - Премияне бирү буенча тәкъдимнәр әзерләүдә Комиссиягә ярдәм күрсәтү.

3.4. Эксперт советы составына вәкаләтле орган, мәдәният һәм сәнгать оешмалары, мәгариф оешмалары белгечләре һәм Комиссия составына кермәгән һәм Премиягә кандидатлар булмаган җәмәгатьчелек вәкилләре керә.

3.5. Комиссия, документларны тапшыру срогы тәмамланганнан соң, эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә эксперт советына кергән документларны тапшыра.

3.6. Тапшырылган документлар әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүгә Эксперт советы тарафыннан карала.

Эксперт советы аңа документлар тапшырганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә Комиссиягә Премиягә кандидатлар рейтингын (алга таба – рейтинг) тәкъдим итә.

3.7. Сайлап алуга кертелгән Премиягә кандидатлар эксперт советы тарафыннан 10 баллы шкала (0-10) буенча түбәндәге критерийлар буенча бәяләнәләр:

3.7.1. »Вокал (хатын-кыз тавышы)» һәм «Вокал (ир-ат тавышы)» номинацияләре буенча:

профессиональ вокал сәнгате өлкәсендәге казанышлар (0 - 10 балл);

музыкаль программаның башкару осталыгының югары дәрәҗәсе (0 - 10 балл);

югары (урта һөнәри) вокал (музыка) белеме булу (0 - 10 балл);

сәхнәдә 10 елдан да ким булмаган эш тәҗрибәсе булу (0 - 10 балл));

репертуарда Илһам Шакировның музыкаль мирасыннан җырлар булу (0 - 10 балл);

репертуарда танылган татар композиторлары әсәрләре булу (0 - 10 балл);

репертуарда халык җырлары булу (0 - 10 балл);

массакүләм мәгълүмат чараларында уңай публикацияләр, рецензияләр, бәяләмәләр булу (0 - 10 балл).

3.7.2. »Халык җыры» номинациясе буенча:

Татарстан Республикасының татар музыка мәдәниятен популярлаштыруга керткән өлеш (0-10 балл);

башкару уникальлеге, стиль үзенчәлекле (0 - 10 балл);

яңалыклар һәм оригинальлек (0 - 10 балл);

массакүләм мәгълүмат чараларында уңай публикацияләр, рецензияләр, бәяләмәләр булу (0 - 10 балл).

3.8. Рейтинг игълан ителгән номинациядә Премиягә кандидатлар җыйган баллар саны нигезендә формалаштырыла. Балларның гомуми саны әлеге

Нигезләмәнең 3.7 пунктында күрсәтелгән критерийлар буенча Премиягә кандидатлар җыйган балларны суммалау юлы белән билгеләнә.

Илһам Шакиров исемендәге
Республика премиясе турындагы
нигезләмәгә 2 нче кушымта

Форма

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин,_______________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булганда)
түбәндәге адрес буенча яшәүче:

_________________________________________________

____________________________-----
(шәхесне раслаучы документ: паспорт, номер сериясе, бирелгән),
«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясен бирү буенча комиссиягә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә, ягъни автоматлаштыру чараларын кулланып яисә шундый чараларны кулланмыйча шәхси мәгълүматлар белән башкарылучы теләсә нинди гамәлләр (операцияләр) яисә гамәлләр (операцияләр) тупланмасын кылуга, шәхси мәгълүматларны җыю, язу, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), чыгару, куллану, тапшыру, (тарату, бирү, кертү), зарарсызлау, блоклау, бетерү, юк итүгә рөхсәт бирәм.

Мин чит кеше исеме яки чит кеше исеменнән (шәхси зат яки оешма) күрсәтелмәскә, өченче затларны идентификацияләүче яки өченче затларга караган дөрес булмаган мәгълүматны күрсәтмәскә тиеш.

Мин түбәндәгеләр белән таныштым :

1) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык әлеге килешүгә кул куелган көннән гамәлдә була;

2) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык минем язма гаризам нигезендә ирекле рәвештә кире алынырга мөмкин;

3) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык алынган очракта, Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясен бирү комиссиясе «Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законда күрсәтелгән нигезләр булганда, шәхси мәгълүматларны эшкәртүне дәвам итәргә хокуклы;

4) Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясен тапшырганнан соң шәхси мәгълүматлар законнарда каралган документларны саклау срогы дәвамында саклана.

Минем шәхси мәгълүматларны эшкәртү «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 52-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп, Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясен бирү комиссиясе тарафыннан башкарыла.

«____» ________20_____ел  __________________ / ___________________________
(имза) (Ф.И.О. (соңгысы - булганда)

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар
Кабинетының 2020 ел, 22 август, 723 нче карары
белән расланды

Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясен бирү комиссиясе турында нигезләмә

1.1. Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясен бирү комиссиясе (алга таба - Комиссия) функцияләре :

Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясе (алга таба - Премия) турындагы Нигезләмә нигезендә гаризалар һәм документлар кабул итә башлау турында белдерү;

Премияне бирү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертү;

бүләкләү документларын рәсмиләштерүне һәм тапшыруны, Премияне түләүне оештыру.

1.2. Премиягә дәгъва кылучы Комиссия әгъзалары Комиссия составында эшләүләрен туктаталар.

1.3. Комиссия утырышлары аның составының өчтән ике өлеше булган очракта хокуклы дип санала.

1.4. Премияне бирү турындагы Комиссия карары Комиссия утырышында катнашучылар арасыннан күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм тиешле беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Комиссия әгъзаларының тавыш бирү нәтиҗәләре тигез санны тәшкил иткән очракта, Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

Беркетмә Комиссиянең тавыш бирүдә катнашкан барлык әгъзалары тарафыннан имзалана, Комиссия утырышында рәислек итүче тарафыннан раслана.

1.5. Комиссия Эксперт советы тарафыннан Премиягә кандидатлар рейтингы тәкъдим ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә Премияне бирү турында карар кабул итә.

1.6. Премияне бирү турындагы Комиссия карары Премия бирү планлаштырыла торган елның 10 гыйнварына кадәр Комиссия тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелә.

Татарстан Республикасы
Министрлар
Кабинетының 2020 ел, 22
август, 723 нче карары
белән расланды

Илһам Шакиров исемендәге Республика премиясен бирү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Шәйхразиев Васил Габделгаяз улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, комиссия рәисе |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры, комиссия рәисе урынбасары |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Гатауллин Риф Хоббул улы | композитор, Татарстан Республикасы үзешчән композиторлар иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (килешү буенча) |
| Зәйдуллин Ркаил Рафаил улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык шагыйре (килешү буенча) |
| Зарипова Руфия Киаметдин кызы | Илһам Шакировның туганы (килешү буенча) |
| Низамова Ләйсән Гаптелхан кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы |
| Сөнгатуллина Зилә Даян кызы | «Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең вокал сәнгате кафедрасы мөдире, Татарстан Республикасының халык артисты (килешү буенча) |
| Фәйзрахманов Айдар Фәтхрахман улы | «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең сәнгать җитәкчесе, |

| | |
|---|---|
| | Россия Федерациясенең атказанган артисты, Татарстан Республикасының халык артисты (килешү буенча) |
| Фәтхетдинов Салават Зәки улы | «Казан дәүләт мәдәният институты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең режиссура, актерлык осталыгы һәм татар театр эстрадасы кафедрасы профессоры, Россия Федерациясенең атказанган артисты, Татарстан Республикасының халык артисты (килешү буенча). |

_______________________